СОВЕТ МОРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **с.Морты** **КАРАР**

№ 17 «22» декабрь 2025ел

Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге Советының 28.04.2018 елның 114 номерлы «Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»карарына үзгәрешләр кертү турында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында «28.03.2018 ел, № 182 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25.11.2025 ел, № 994 карары нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр, муниципаль хезмәткәрләр", Морт авыл җирлеге советы

КАРАРЫ:

1. Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге Советының «Алабуга муниципаль районы Морт авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 28.04.2018 ел, № 114 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:;

1.1. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3.2. Муниципаль хезмәткәрләргә вазыйфаи окладлар, биләгән муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладына тапкырланган күләмнәрдә 16 928 сум күләмендә билгеләнә.».

1.2. Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

."Нигезләмәгә 1 нче кушымта

«Алабуга муниципаль районының Морт авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә башлыкны, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затлары айлык акчалата бүләкләү күләмнәре

| ВАЗЫЙФАЛАР ИСЕМНӘРЕ | АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ, СУМНАРДА |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 23 201» |

1. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш һәм 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Рәис урынбасары Д. Ш. Нуриәхмәтов

Совет Мортовского сельского поселения